


*Хәерле көн, апам!*
*Хәерле көн, мәктәбем!*



# РОБЕРТ МИ4НУЛЛИН

**Әни кирәк**

Көннәр якты булсын өчен,
Йокы татлы булсын өчен
Әни кирәк!
Җил-яңгырдан саклар өчен,
Усаллардан яклар өчен
Әни кирәк!
Ашлар тәмле булсын өчен,
Дөнья ямьле булсын өчен
Әни кирәк!
Гөлләр чәчәк атсын өчен,
Бәхет-шатлык артсын өчен
Әни кирәк.
Иң кадерле кеше җирдә —
Әни, димәк!




Роберт Миңнуллин

# *Кереш сүзләр – вводные слова*

- Минемчә – по-моему
- Минем фикеремчә – по моему мнению
- Минем уйлавымча – по моему мнению
- Әлбәттә – конечно
- Кызганычка каршы – к сожалению
- Бәхеткә каршы – к счастью
- Киресенчә – наоборот
- Димәк – значит

# Кереш сүзләр:

* **1.** Сөйләүченең җөмләдәге уйга булган мөнәсәбәтен белдерә торган сүзләр.
* **2.** Җөмләне укыганда аларны төшереп калдырырга да мөмкин.
* **3.** Аларга җөмләдә сорау куеп булмый.
* **5.** Сөйләмдә алар бик аз сиземләнә торган интонация һәм пауза белән әйтелә.
* **6.** Язуда өтер белән аерылалар.

# *Кереш сүзләр янында тыныш билгеләре: (өтер)*

* - җөмлә башында килгән кереш сүздән соң өтер куела;
* - җөмлә уртасында килгән кереш сүзләр ике яктан да өтер белән аерыла;
* - җөмлә ахырында килгән кереш сүзләр алдыннан өтер куела.









Тест

1. Нинди сүзләргә кереш сүзләр диләр?
А) сөйләмгә мөнәсәбәтеңне, үз фикереңне белдерү өчен кулланылган сүзләргә;
Ә) башка телгә тәрҗемәсен күрсәтү өчен кулланылган сүзләргә;
Б) җөмләне матур итү өчен кулланылган сүзләргә.
2. Кереш сүзләр янында нинди тыныш билгеләре куела?
А) сызык;
Ә) нокта;
Б) өтер.
3. Кереш сүзләр җөмләнең кайсы урынында киләләр?
А) башында, ахырында;
Ә) уртасында, ахырында;
Б) башында, уртасында, ахырында.
4. Кереш сүзнең рус теленә тәрҗемәсен табыгыз.
Минемчә –
А) по-моему мнению;
Ә) по-моему;
Б) по-твоему.
5. Җөмләгә төшеп калган кереш сүзне куегыз.
..., без әниләребезне яратырга, хөрмәт итәргә тиешбез.
А) димәк;
Ә) киресенчә;
Б) бәхеткә каршы.

# *Җаваплар:*

* **1) а**
* **2) б**
* **3) б**
* **4) ә**
* **5) а**

# Өй эше.

Кереш сүзләр кулланып, әниләр турында хикәя яза аласыз, яки Айдарга «Й5зек кашы» повестенн9н характеристика яза аласыз.

# Дәрес бетте.

# Сау булыгыз!